**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"23" ноябрь 2019 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-Комыргуҗа авылы зиратын чистарту өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылын чистарту,төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылындагы чишмә эйләнәсен төзекләндерү өчен чыгымнар тоту;

-Комыргуҗа авылында урамнарны яктырту һәм яктырткычлар, материаллар сатып алу (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) буенча хезмәт күрсәтү;

-Комыргуҗа авылында урам тренажёрлары алу һәм урнаштыру.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.

СОВЕТ КОМЫРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ИНН 1610000733